# ТУГАН АВЫЛЫМ

*ТАҺИР ШАРИПОВ  көе*
*НӘҖИП ИДЕЛБАЙ   сүзләре*

Туган авылым минем,
Куенында синең
Гөрләп үтте үсмер елларым.
Кырларың хуш илсе,
Һәрчак язлар төсле,
Шунда туды тәүге җырларым.

Инеш буең ямьле,
Суларың тәмле,
Җилләрең дә назлы ягымлы.
Айлы кичләрең дә
Әле исләремдә.
Яратам мин туган ягымны.

Яланнарың иркен,
Авылымның күрке
Сызылып аткан алсу таңнарың.
Һаман синдә күңел,
Онытырлык түгел
Сайрар кошларыңның моңнарын.